**Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА**

# КАРУРМАНДА ЯЛГЫЗ КИЕК ЭЗЕ

Кулыма берчак Хәмит Латыйфның 2006 елны дөнья күргән «Галәми гамь» исемле китабы килеп керде. Олы бер дөнья – мин белмәгән, әле мин танымаган чиксезлек сыман. «Сынлы сәнгать һәм шигырьләр» дигән алтынсу язу үзе үк игътибарны җәлеп итә. Кызыксынып тәүге битләрен ачып карадыңмы, тиз генә ычкынырмын димә бу гамь ташкыныннан. Төрле стильдә язылган картиналар, керамика һәм агач эшләнмәләр, сыннар һәм шигырьләр – чиксезлек сулышы, галәм гаме бөркелә торган әсәрләр дисәм, ялгышмамдыр.

Үзе белән көрешкән чакта, иң элек, Хәмит абыйдан шигырьләр яза башлау тарихы турында кызыксынасы иттем. Уфада яшәгән чорда бик каты авырый ул беразаман. Тән температурасы югары, башта тонык томаннан башка гайре берни юк. Хәлсезләнеп атналар буе чирләп ятакта аунаган авыру ирнең күңеленә шигъри юллар килә. Ирексездән каләм-кәгазь алып, язарга керешә ул. Шыбыр тиргә батып, изаланып яза да яза. Савыга, аякка баса, әмма шигырь «җененнән» инде котыла алмый. «Җир һәм күк» (шушы исем белән тәүге шигырьләр китабы Туймазыда 1997 елны дөнья күрә), «Көмеш бәллү», «Өмет кузы» шигырь цикллары – картина, сыннарда җиткерергә омтылган идея-фикерләренең кайтавазы ул. Хәмит Латыйф – җанындагы яраларын иҗат белән дәвалаучы, йөрәген бимазалаучы гомерлек сагышларын сын-сурәтләргә, рәсемнәргә, шигырьләргә түгеп юанучы. Дөньялыкның вак-төяк кыйммәтләреннән үз иҗат дөньясына качып, яраларын ялгыз ямаучы кыргый карурман киеге ул…

> Рәссам бага урман күзләренә,
> Урман күзе
> Тиз арада багар киндердән. («Бербөтенлек», 1996)

Карурман күзләренә бик яшьли багарга туры килә Хәмиткә. ...Урман юлыннан төн ката 6 яшьлек малай белән киң җилкәсе сынган кош канатыдай салынып төшкән уйча ата кеше бара. Йорт салырга бүрәнәлек агач кирәк. Әтисе аудаган озын агачларны Хәмит ботак-сатактан арындыра, аннан шул бүрәнәләрне икәүләп ихатага алып кайтасы. Үр менгәндә бүрәнәләрне тәгәрәтү таза-сәламәт ирләргә дә авыр эш. Сугыштан гарипләнеп кайткан ата кеше һәм сабый малай җан көчләре белән үргә бүрәнә тәгәрәтә. Кайвакыт ул бүрәнә орчыктай Хәмитне читкә атып бәреп, түбән тәгәри. Таң сызыла, тәрәзләр уяна башлаганчы, бүрәнәләрне бәрәңге бакчасына күмәсе дә бар бит әле. Киләсе төнгә кабат урман күзләренә багасы. Илереп, тилмереп, үҗәтләнеп!

Ә йорт кирәк, бик кирәк! Черек нигезле, җылы сакламый торган иске өйдә кышларын түзәр хәл юк. Хәмит сәкедә бөгәрләреп бетеп, юрганга күпме генә төренеп маташмасын, рәхимсез суык үзәкләргә үтә, тәнне генә түгел, җанны да калтырау ала төсле. Кыш салкыны гына түгел, ятимлекнең әче суыгы

шулай тилмерткәндер 7 айдан әнисез калган сабыйны. Үҗәтләнеп, мөгаен үзе дә аңламаган бер көч белән атлый ул тормыш дигән карурманга. Нәни куллары белән балта тоткан, елый-елый бүрәнә юнган, пычкы тарткан малайның агачны үз итүе гаҗәпме? Туган ягы агачларына тәүге маңгай тире белән бергә, әрнүләрен сала бит ул. Өч ел дигәндә изаланып җиткезелгән йорт – Хәмитнең тәүге иҗат эше булгандыр – ятимлекнең ачы күз яшьләрен сыйдырган беренче әсәре. Киләчәктә дә иҗатында нәкъ менә агачны – гади, гүяки җанлы чималны үз итүе гаҗәп түгел. Сандык-тартмалар, агач панно, савыт-саба, йорт җиһазлары, ишек бизәкләре, милли курчаклар – агачта һәм агачтан иҗат иткән әсәрләре бихисап аның. «Кулга агач түмәре алу белән, анда ниндидер җан ияләрен, бизәкләрне күзаллыйм. Күңелгә килгәнне кул ясый. Мин түгел, әйтерсең кулларым үзе эшли,» дип гади генә аңлата Хәмит агай үзе бу осталыгын. Сабыйлыктан балта тотып үскән бармаклар шул алар. Авыр хезмәттән, дөнья йөгеннән күңел зәвыгын һәм нечкәлеген югалтмаган йөрәк шул. Әнә шушы куллар ясаган ишек бизәкләреннән бичуралар, урман, су ияләре, рухлар бага; төнката карурманга утынга килгән егетне таягын имән тамырына терәгән урман иясе сынап каршылый, шүрәле көлә, су анасы дулкын чәчен тарый... Агач сыннарда ялгыз чаптар хуҗасына дәшә («Ераклардан чакыру»), түбәтәйле егет дөньясын онытып курай уйный («Мин тыңлыйм»), сердәш хатыннар – аркадашлар кич утырып йон эрлиләр («Аулак өй»), маңгаена гомер буразналары салынган моңлы карашлы агай туган йортындагы каз оясына сыена («Кош оясы») – гамь, милли гореф-гадәтләр салынган көнитешнең гаҗәеп җылы тасвир-сурәтләре, табышмаклар алар. Агачка уеп бизәкләр ясау, эшләнмәләр әзерләү тәҗрибәсен, серләрен киләчәк буыннарга сабак итеп калдырырга омтыла Хәмит агай. Әнә шул игелекле максат белән «Уелган бизәкләр» («Резба по дереву») исемле китап та әзерләгән. Бүгенге көндә бөтен өзгәләнгәне – шул хезмәтне дөньяга чыгару, басыру, аның укучы кулына барып ирешкәнен күрү. Гомеренең сигезенче дистәсенә аяк баскан аксакал әдипнең әлеге мөкаддәс хыялы чынга ашсын иде. (Заманыбызда Рәмиевләр, Хөсәеневлар кебек милли гамь белән янган сәнгатьсөяр хәйриячеләр бардыр. Бәлки бу сүзем алар хозурына да барып ирешер…).

Карурман – татар үзаңы өчен сакраль образ. Халык авыз иҗатына, җырларга, әкиятләргә салынган карурман һәр күңелдә яши, үзенчә ачыла, әмма кайтаваз булып чорлар аша каннарда аваз салудан туктамый. (Туктый да күрмәсен, берүк!) Карурман – хөрлек, сер, терәк, яшерүче, саклаучы да, рух көчеңне, иманыңны сынаучы да. Карурман мотивы Хәмит Латыйпов иҗатында үзәк урынны алып тора: сынлы сәнгать әсәрләрендә дә, шигъриятендә дә. Сабыйлыктан ук күңеленә сеңгән, туган авылы Бүләр карурманнары аша җанына уелгандыр бу хиссият. «Туган моңнар» (1997), «Шагыйрь» (1996), «Урман көе» (1996), «Туган ил турында җыр» (2005), «Ялгыз» (2005) һәм башка бик күп картиналарындагы образлар урман кочагында сурәтләнә. Урман, агачлар – милли мотив булу белән бергә, туган җир, туган як символы буларак та укыла. Туган авылын юксыну – Хәмит Латыйф иҗатын хәрәкәткә китерүче олы бер көч ул.

...13 яшендә Хәмит әтисез дә кала. Ватан сугышында, әсирлектә ярты саулыгын калдырып кайткан Нәҗип солдатның гомере кыска була шул. Интегеп салынган өйдә үги әни һәм нәни энесе белән кала Хәмит. Нишләптер үз итә алмый ул бу әнкәне. Өйдә мөмкин кадәр сирәгрәк булырга тырыша, туган-тумача, күрше-күләндә кунып калгалый. Ахыр чиктә, 15 яше тулар-тулмас үсмер авылдан ук чыгып китә. Тормыш белән күзгә-күз, үз көнен үзе күрә башлый. Әмма авыл – рухи терәк, нигез булып кала бирә. Юлсызлыкка карамый, яңгыр-буран дими, еш кайтып егыла Хәмит Буләргә. Тик аны биредә беркем өзелеп көтми, ул берәүгә дә кирәкми шул. Кайтып берничә сәгать үтүгә шушы ачы хакыйкатькә кабат күңеле белән төшенеп, зират каеннары белән серләшә дә, янә юлга кузгала. Буләр – аны ятимлек ачысы, авыр хезмәт белән чыныктырган да, карурманлы, Кызылъярлы яшел бишегенә салып тибрәткән дә, нигез кыйммәтләрне дә төшендергән туган авылы 70нче еллар ахырында юкка чыга, бетерелә. Аның киләчәге белән бергә, Хәмит күңелендә дә иң нечкә кыллар шартлап өзелгәндер. Бик яшьли ата-анадан калган ятим егеткә үксезлекнең иң ачысын – нигезсез, җирсез калуны да кичерергә туры килә. «Авыл беткәч, миңа бөтен нәрсә юкка чыккан кебек тоелды. Мин җир белән күк арасында асылынып калдым. Мин илсез кеше идем. Ялгызлыктан да кара дөнья булмыйдыр...», дип яза бу хакта истәлекләрендә. Ун еллап гүя томан эчендә яши рәссам – чарасызлык, төкәнмәс сагыш томанында. Җирсү хисен иҗатка, әсәрләренә бушатып юана. Шул җирсү, төсләр булып та, сүзләр булып та, уем-бизәкләр булып та Хәмит Латыйф иҗатының мәгънәви катламына языла. «Чакыру» (1999), «Кичке җыр» (1997), «Моңлану» (1997), «Кайтаваз» (1995), «Кымыз эшләгәндә» (1999), «Табигатькә мәдхия» (2005), «Иске дус» (2003), «Җәйләүдә» (2003), «Авылдашлар» (2005) һ.б. әсәрләре – туган авылын юксыну сурәтләре алар.

Дөньясыннан йөрде нидер эзләп,
Телде җанын тарих ярасы.
Бер җанына һич табалмый урын
Татарның бер өтек баласы. («Татар баласы», 1998)

Рәссам-сынчы иҗатында туган җиргә булган чиксез мәхәббәт үз халкын сөю буларак та тәгаенләшә. Кайсы гына образны алма – читекле, кәләпүш-калфаклы, милли киемнән, күзләренә гамь сөрмәсе тартылган булыр. Рәссам Хәмит Латыйпов иҗаты белән тамырларны, туган халкы тарихын барларга, үткәндәге милли кыйммәтләр призмасы аша киләчәккә күз салырга омтыла. «Ак бүре» (1997) рәсеме – төрки халыкларның килеп чыгышы хакында билгеле риваятькә нигезләнеп ясалган рәсем-картина. Ярымайга үрелгән, гүяки сыенган ана бүре. Алтынсу ай нуры аның күзләрендә үк чагыла. Айдан иңгән шушы нур белән ике сабыйны имезә ул. Бүре образы – тарихи хәтер белән туендыручы игелекне ана. Аның аклыгы караңгы төн фонында аеруча гүзәл һәм пакъ яктылык булып тоела – караңгы пәрдә каплаган тарих төпкелендәге хәтер яктылыгы булып.

Һәр иҗат әһеле хакыйкатьне эзли. Рәссам, сынчы, агачка уеп эшләүче буларак, Х.Латыйф хаклык тамырларын эзләп халык риваятьләренә, миф-легендаларга, йола-гадәтләргә, ырым-ышануларга, дини күзаллауларга мөрәҗәгать итә. Шуңадырмы, аның әсәрләре сер белән өретелгән. Баккан саен һәм гомернең һәр чорында төрлечә укыла торган картиналар, сыннар, уем-бизәкләр тәшкил итә бу сер ачкычларын.

Янә бер кызыклы иҗат үрнәге – «Күл буенда» (1995) картинасы – рәссамның милли җирлектә гомумкешелек кыйммәтләре, нигез төшенчәләр турында уйланып язган программ әсәре. Үзәктә – көянтә-чиләк аскан, ак яулыгын япкан милли киемле татар кызы. Ул күлгә коя торган чишмә башында тора. Чиләкләренең рәвеше дә, зурлыгы да төрле, кыз үзе дә уң аягы белән коры җиргә, сулы белән суда басып тора, чиләкләрен тотышы да төрлечә. Артында махсус кыек рәвештә ясалган пирамидалар, яртылаш күлгә баткан кояш, күл дә җырдагыча түгәрәк түгел. Шушы аварга торган дөньялыкны тотып торучы бизмән-көч – хатын-кыз. Бер ягында үрдәк (әлеге символны җир шарының күлдән үрдәк томшыгында чыккан бер бөтек туфрактан бар булуы турында риваятькә ишарә дип кабул итәргә кирәктер), икенче ягында яшь үсенте, димәк ки, киләчәк. Җир һәм кешелек, шул исәптән милләт киләчәге дә, әлеге киләчәкнең нинди булуы да хатын-кыз – тереклек булдыручы ана кулында. Тарихи хәтер белән киләчәкне тоташтыручы буларак та, тормыштагы тигезлекне, гармонияне саклаучы булып кабул ителә бу әсәрдә хатын-кыз образы.

Ана – Хәмит Латыйпов иҗатында үзәк образларның берсе, иң әһәмиятлесе. Әнкәсен хәтерләми, ул күкрәк баласы чакта ук әнисе Мофаза яшьли дөнья куя. Язмыш шулай мәңгелек сагышка, төзәлмәс гомерлек җан ярасына дучар итә сабыйны. Еллар үткәч, «Мин әле үлмәдем...» дигән шигырь язар ул. Әнкәсе турында. Гүя, хактан да, җиргә китергән кадерле кешесе үлмәгән, иҗат ялкыны булып Хәмитне гел гомере буе озата бара. Иҗатын аңлыйм дисәң, иҗат әһеленең тормыш-булмышын, бигрәк тә сабыйчак яраларын барлау кирәк. Шушы ятимлек ачысы Хәмит Латыйповны күренекле рәссам-сынчы һәм шагыйрь иткән дә, шиксез.

Сабый-сабый сабыем,
Сабыр бул син, сабыем.
Сабыр төбе – сары алтын,
Алтын бул син, наныем… («Бишек җыры», 1995)

Хәмит Латыйпов 1996 елны «Төш» дигән картина яза. Әнкәсенең өрфиядәй, сулышың белән ялгыш өрсәң дә таралырдай хыял-сынына сыенган яланаяклы сабый. Төштә генә кочагына алып иркәли торган мәрхүмә әнисе – әйтерсең, малайны күк, ай, галәм белән тоташтырып, галәми гамьнәр иңдереп торучы фәрештә. Әнә ич, иңнәрендә канатлар да шәйләнә. Ә дөнья әйләнә дә әйләнә, төсләре чуар-чуар. Шушы туктаусыз зыр әйләнгән мең төсле дөньялыкта бердәнбер ак һәм саф җылылык – Ана мәхәббәте. Рәссам үзе

иҗатында – хыялында гына йөрәгеннән җылыта алган тансык җылылык бу. Әмма һәр иҗат әсәреннән бөркелеп торган җылылык.

Әнә шундый күңел багажы белән шактый юллар үтә, байтак шәһәрләрдә тормыш корып карый, иҗат итә Хәмит агай. Мәскәү янындагы Загорск районының Богородск авылында агачтан уеп эшләү алымнарын үзләштерә, Уфа сәнгать училищесында белем ала, Туймазыда яши һәм остазлык итә, Казанның «Туран» оешмасында иҗаты белән хезмәт куя. Аннын Чаллыга килеп төпләнә, остаханәсе биредә. Галәм гаме белән сугарылган иҗат, шөкер, дәвам итә.

Бу китаптагы әсәрләр оста гомеренең һәр чорыннан, Хәмит Латыйфның шәхси архивыннан. Алар аласында 1973 елда Уфадагы сәнгать көллиятенә кергәнче үк язылган рәсемнәр дә, 1983 – 1985 елларда Туймазыда фарфор заводында эшләгән чорда иҗат ителлгәннәре дә һәм аннан соңгы чорда ясалган эскиз-рәсемнәр дә бар. Моңлы һәм сагышлы иҗади язмышның һәр чоры үзенчә кызыклы һәм кадерле.

Шигырьләр дә – шагыйрь гомеренең һәр дәвереннән. Шагыйрь буларак та Хәмит ага дөньяны төсләр, образлар аша күрә. Гади генә төсмер-сурәтләрдә күңелне сискәндереп җибәрерлек фикер табуы, тормышның вак детальләре аша олы хисләрне, гамьнәрне аңлата, искәртә алуы белән кызыклы әсәрләр алар. Үкенечләр, өметләр, үксезлек ачысы, каралыктан-яманлыктан чиркану тулы һәм ил-җиргә, кешелеккә карата чиксез мәхәббәт белән өретелгән. Әлеге шигырьләр ятимлек хәсрәте, ачысы белән тормышка олы мәхәббәт катыш. Алар гүя шушы ике олпат хиснең каршылыгы нәтиҗәсендә шагыйрь җаннын саркылып чыккан.

Хәмит Латыйф иҗаты: һәм шигырьләре, һәм сурәт-картиналары – гаҗәп ихлас. Аларны бер-берсеннән аерып карау мөмкин түгелдер, һәм бу кирәкми дә. Алар – бербөтен. Шушы бөтенлеге тулы бер эпоханы колачлыйлар – шәхес гомерен дә, милләт язмышын да, чор сулышын да. Алар – җир һәм күк арасында үз яралы җанына, өметләренә урын таба алмый бәргәләнүче сагышлар. Һәм, әлбәттә, бу сагыш – рәссам-шагыйрьнеке генә түгел… Шуңа күрә дә, Укучы хозурына тәкъдим ителгән әлеге китап гади генә «Сагышларым» дип атала. Рәхим итеп, кабул кыл – анда, шөбһәсез, Синең дә сагышларың бар.

«Минем иҗат, гомерем кебек үк, гел кыл өстеннән йөрде… Мине бу җирдә Ходай һәм күңел, иҗат кына саклап калгандыр, дип уйлыйм». Аксакал рәссам-шагыйрь сүзе бу. Әрнү-яраларыннан галәм гамьнәре саркырлык матурлык тудыра алган ялгызак карурман киеге сүзләре. Күңелләр ихласлыгын, хөрлеген һәм гүзәллеген саклый торган ул карурманда Хәмит Латыйф дигән рәссам-шагыйрьнең җуелмас эзләре бар. Бар!

*// Мәйдан. – 2020. – № 1. – Б.132-138.*